КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 16 февраль г.Казань № 111

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре дәүләт эшләренә, хезмәт күрсәтүләренә һәм дәүләт хезмәтләре күләмнәренә норматив чыгымнарны раслау турында» 2025 ел, 26 сентябрь, 767 нче карары белән расланган 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре дәүләт эшләренә, хезмәт күрсәтүләренә һәм дәүләт хезмәтләре күләмнәренә норматив чыгымнарны раслау турында» 2025 ел, 26 сентябрь, 767 нче карары белән расланган 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының кайбер дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарга, 2.2 пункттагы «вазыйфаи затларга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә

органнарына һәм дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру» юлының 4 графасында «377 181 830,0» саннарын «385 922 930,0» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин